…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

**1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.**
**№ 4 2013. Декабрь**
**«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге**

## 12 нче декабрь – Россия Конституциясе көне




*1993 елның 12 декабрендә кабул ителгән Төп закон кешене, аның гражданлык хокукларын һәм демократик ирекләрен иң зур хәзинә дип игълан итте*

Егерме ел элек бу көнне Россия Конституциясе кабул ителде.. Конституциядә сәламәтлекне ныгытуга, белемгә, сүз ирегенә хокуклар регламентланып кына калмаган, ә гарантияләнгән. Конституциябезнең төп принциплары илебезнең тотрыклы үсешен, дәүләтнең нигезле икәнен гарантияли. Россиядә барлык законнар Конституциягә каршы килмәслек итеп эшләнә. Төп закон кабул ителгәннән соң узган 20 елда илебез, республикабыз, шул исәптән районыбыз социаль-икътисадый һәм иҗтимагый-сәяси үсештә зур үзгәрешләр кичерде. Икътисадтагы уңышларыбыз яңадан-яңа башлангычлар һәм аларны гамәлгә ашыру өчен уңай мөмкинлекләр ача. Конституция нигезендә мөһим социаль программалар гамәлгә ашырыла, тормышыбызга яңа технологияләр актив үтеп керә, гражданнарыбызның иҗади сәләтләрен ачу, төрле милләт вәкилләренең татулыгын, дуслыгын ныгыту өчен шартлар тудырыла. Хокукларыбыз безгә бурычлар да йөкли. Барыбыз да күпмилләтле илебезнең киләчәге өчен җаваплылык тоеп, Конституция нормаларын белергә, ихтирам итәргә һәм үтәргә бурычлы.

Хөрмәтле укытучылар, укучылар! Сезне ихлас күңелдән Конституция көне белән котлыйбыз. Исәнлек-саулык, иминлек, бәхет, күңел көрлеге һәм матур тормыш телибез. Илебезнең төп Канунының һәр маддәсе үтәлсен, Конституция халыкка хезмәт итсен.

## *ДУМА ЯҢАЛЫКЛАРЫ*

**Үткән атнада дума тарафыннан берничә акция уздырылды. Беренче акция Әниләр көне уңаеннан “Икелеләрсез атна” дигән исем астында үтте. Атна буена һәр сыйныфта акциянең узышын мәктәп балалар думасы оешмасындагы укучылар күзәтеп барды. Шимбә көнне нәтиҗә ясалды. Билгеле булганча иң күп “икеле” 9 нчы Б сыйныфы (15) һәм 8 нче сыйныфлар (7) “икеле” эләктергән. Ә бер “икеле” дә алмаучылар 10 сыйныф икән. Икенче акция исә көндәлекләрнең торышы һәм дәреслекләрнең сакланышы буенча иде. Кызганыч, бу акциядә беренчелеккә чыга алырлык сыйныф табылмады. Һәр сыйныфта көндәлек тутыруга җитди карамаган яисә дәреслекторышына тавапсыз караучылар бар икән... Мондый акцияләр алдгы көннәрдә дә дәвам итәчәк. Кимчелекләрне төзәтәсе иде. Икенче рейдтан соң фамилияләр конкрет әйтеләчәк.**

*БУ АЙДА... фән олимпиадаларының район туры дәвам итә. Инде күп фәннәрдән нәтиҗәләр билгеле булды. Уңышлы чыгыш ясаучыларны гомуми нәтиҗә белән бергә атарбыз.*

*БУ АЙДА... 4 нче сыйныф укучылары мониторингта белемнәрен тикшерде..*

*БУ АЙДА... 5-11 нче сыйныф укучылары онлайн-тестирование үтте, белемнәренең нигезен бәяләде.*

*БУ АЙДА... яңа елга әзерлек башланды!!!*

# ОСТА КУЛДАН ЭШ КУРКА.

Нәрсә ул бәйләү? Сәнгатьме яисә хоббимы? Минемчә, сәнгать. Үз кулың белән бәйләгән әйбер, бәйләүченең кул җылысын, шул әйберне бәйләгәндә салган мәхәббәтен саклый. Бәйләүче ул – рәссам. Бәйләүченең инәсе, ыргагы, рәссамның пумаласы кебек үк, гадәти булмаган сурәт тудыра, ә кулдан ясалган әйбер ул бик үзенчәлекле һәм беркайчан да модадан артта калмый.бәйләү кешегне тынычландыра, кәефен күтәрә, сабырлык һәм ихтыяр көче тәрбияли.

Мин дә бәйләргә яратам. Мине бу эшкә апаларым – Тәслия һәм Җәүһәрия тартты. Мин аларның күз иярмәс тизлектә ыргак йөртүләренә сокланып һәм кызыгып карый идем. Үземне дә өйрәтүләрен сорадым. Башта җиңел үрнәкләр, соңрак авырракларны, ә бераздан пәрәвез җәтмәсендәй схемаларны да укырга өйрәндем бит. Бу шөгыль мине үзенә әсир итте, яңадан-яңа үрнәкләр, модельләр эзләдем, аларны үзем сынадым.

Заман белән бергә бәйләү технологияләре дә алга китте. Яңа машиналар уйлап таптылар. Кибеттә дә бәйләгән әйберләрнең очы-кырые юк. Ләкин нигәдер үз кулың белән бәйләгән киемнәр сатып алганына караганда күпкә күңелгә ятышлы...

**Галимова Алсинә 10 нчы сыйныф укучысы**



*Алсинә безгә үзенең эшләреннән берсен тәкъдим дә итте – болар кулдан бәйләнгән кедылар. Шәп бит? Кулларыңнан куан, Алсинә!*



## Әдәби почмак



Конференция мизгелләре



### КОНФЕРЕНЦИЯДӘ КАТНАШТЫК.

***11 нче декабрь көнне Лениногорск районы Шөгер авылының Чкалов исемендәге гимназиядә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинның иҗатына багышланган республика күләм иҗади – гамәли конференция үткәрелде. Конференция кысаларында алдан игълан ителгән бәйге нәтиҗәләре, шагыйрь белән очрашу, секцияләрдә түгәрәк өстәл утырышлары уздырылды. Безнең мәктәптән дә әлеге конференциягә чакырылучылар бар иде. Безнекеләр биредә дә сынатмады. “Шагыйрь иҗатына анализ” номинациясендә 9 нчы сыйныф укучысы Абунагимова Айгөл 1 нче урын, “Шагыйрь иҗатын дәрестә куллану” номинациясендә Ралия апа Газимҗанова 3 нче урынны яулады. Калган барлык катнашучылар да “Катнашучы таныкланамәсе” электрон форматта тапшырылачак диделәр. Роберт ага Миңнуллин әле автографлы китапларын да бүләк итте. Очрашу бик җанлы, мавыктыргыч булды. Без дә кунакка чакырдык аны, ләкин әле вакыты тарлыгын сылтау итеп, ул чакыруны кабул итмәде. Ә Ранинең шигырен ошатты, хәтта “Шигырьләреңне җибәр, бернчетәнкыйтчең булырмын!” – дип электрон адресын да бирде.***

***Газимзянова Гөлинә. 7 нче сыйныф укучысы***

**“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015**

# Тырышсак

## Безнең кызлар иң уңганы



Мәчеттәге чара мизгелләре



*6 нчы декабрь көнне Чирмешән мәчетендә кул эшләре буенча игълан ителгән бәйгегә, ниһаять, нәтиҗә ясалды. Бу бәйгегә безнең кызларыбыз да үз эшләрен тәкъдим иткән иде. Монда да сынатмадык. Камалова Зөлфия, Закирова Миләүшә, Газимзянова Гөлинә, Сруртдинова Ләйләләр үзләренең эшләре өчен Диплом һәм кыйммәтле истәлек бүләкләре белән бүләкләнделәр. Ә менә Нуртдинова Ләйлә барысыннан да уздырды – аның эше беренче урынга лаек булды. Ул бу эше белән күпме күз нурлары түккәндер, әмма беренчелекне алгандагы горурлык хисе барысын каплый. Чара бик эчтәлекле оештырылган иде: Хәбир хәзрәт Ханов безгә бик үтемле вәгазь сөйләде, "Ни чәчсәң, шуны урырсың" исемле фильм карадык. Уйландырырлык тема. Мәңгелек тема. Мин бу фильмны барлык яшьтәшләремә дә карарга тәкъдим итәр идем. Ә аннары җанлы сөйләшү тәмле чәй табыны артында дәвам итте. Әлеге чарада катнашуны, мәчеткә алып баруны оештырган Галия апа Динмөхәммәтовага рәтемне җиткерәсем килә. Шулай ук транспорт проблемасын чишә алган дирекциягә мең рәхмәт. Имин яшик!*

*Рания Газимзянова 9 нчы сыйныф*

## *БИТАРАФ БУЛМЫЙК!!*



Безнең мәктәптән Шакирова Зөһрә һәм Гүзәл Динмөхәммәтова Картлар йортында инвалидлар декадасы уңаеннан оештырылган хәйрия чарасында катнаштылар. Язмыш тарафыннан зур сынауга дучар ителгән апа-абыйлар, әби-бабайлар аларның чыгышын бик яратып кабул итте.



**Янибызда бездән бары игътибарга да шат булучылар бар. Битараф булмыйк!**

# булдырабыз

## КАЗАНЛЫЛАРГА БЕЗНЕҢ ЭШЛӘР БИК ОШАГАН

Казан шәһәрендә уздырылган "Ватан" дип исемләнгән фестиваль Лашман урта мәктәбенең кул эшләре дә күргәзмәгә куелды. "Агач өслеккә бизәк төшерү", "Шома өслеккә чигү", "Чалмалап чигү" номинацияләрендә безнең осталарның иҗади эшләре күрсәтелгән иде. Жюри рәисе –"Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе журналисты, якташыбыз Илдар кыямов – безнең эшебезгә уңай бәя бирде, мәктәбебезгә уңышлар теләде Ләйлә Зөфәрова, Фәйрүзә Гатина, Зөлфия Камалова, Миләүшә Закирова, Ләйлә Сорурдинова фестивальнең дипломанты булдылар.

Миләүшә Закирова 9 нчы сыйныф укучысы



*СПОРТ СПОРТ СПОРТ СПОРТ СПОРТ СПОРТ СПОРТ*

## БЕЗНЕҢ ЙОЛДЫЗЛЫ СӘГАТЬ... ДӘВАМЛЫ!!!

**8 нче декабрь көнендә безнең мәктәптә бик зур чара – район буенча беренчелек өчен баскетбол ярышы уздырылды. Кичтән буран бөтен җиргә кар тутырса да, юлларда йөрү авыр булса да беренчелекне алу теләге көчле булган - көч сынашырга Түбән Кәминкә, Кадетлар, Кутәмә мәктәбе командалары килгән иде. Лашман мәктәбеннән ике команда чыгыш ясады. Уеннар бик мавыктыргыч, дәртле барды. Тырышлык бушка китми шул – кубок бездә калды!!!**

**Рания Газимзянова 9 нчы сыйныф укучысы**




***Кубок – БЕЗДӘ!!!***
***Иң шәп, иң булдыклы егетләр дә бездә!!!***
***P.S. Тиздән район беренчелегенә чаңгы буенча ярышлар һәм йөзү ярышлары була. Үзебезнекеләргә тырышлык, үҗәтлек һәм ЖИҢҮ телим!!!***